ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Кама Тамагы муниципаль районының**

**Тәмте авыл җирлеге Башкарма комитеты**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**Камско-Устьинский муниципальный район**

**Исполнительный комитет Теньковского сельского поселения**

Кама Тамагы районы,
Тәмте авылы
тел. 8-(277)- 31-1-76

Камско-Устьинский район,
с. Теньки
тел. 8-(277)- 31-1-76

# КАРАР

№ 27 27.09.2019 ел

2019 елның 9 гыйнварындагы “Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Башкарма комитетының 1 номерлы Карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

“Федераль мәгълүмати адреслы система турында”гы 2019 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль закон нигезендә һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга үзгәрешләр кертү нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР КЫЛА**:

1. 2019 елның 9 гыйнварындагы “Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Башкарма комитетының 1 номерлы Карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең

Административ регламентына (алга таба - регламент) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.5 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“адрес - Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары нигезендә структуралаштырылган һәм үз эченә шул исәптән урам-юл челтәре элементының һәм (яки) планлаштыру структурасы элементының атамасы (кирәк булганда), шулай ук адресация объектының санлы һәм (яки) хәреф-цифрлы билгеләнешен ала торган адресация объектының урнашу урыны тасвирламасы.;”;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“адресация объекты - капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект;”;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“планлаштыру структурасы элементы - зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе”.

2. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, Октябрь урамы, 65 йорт (АҖ администрациясе бинасы)

ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, 2 нче Октябрь урамы, 50 нче йорт (мәдәният йорты бинасы),

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Җитәкче** **И. А. Зиновьев**